| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17 апрель 2020 ел** Шалты авылы **№ 115**

Баулы муниципаль районының
Шалты авыл җирлеге Советының
17.10.2019 елдан № 96 карары белән
расланган Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
«Шалты авыл җирлеге” муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр
кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2009 елдагы 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 09.12.2009 елдагы 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясына туры китерү максатларында, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» законнарына нигезләнеп, Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Советының 17.10.2019 елдан № 96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«21) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм

төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында Карар кабул итү.»;

21 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары оештыру һәм үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә буенча билгеләнә»;

92 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында " 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен Юстиция органына җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Советы рәисе — Фаткуллин З.Х.